СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

25.04.2016 | с. Верхний Услон | № 10-99

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфалары, федераль дәүләт хезмәте вазыйфалары, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә һәм китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы кабул ителүгә бәйле рәвештә һәм коррупциягә каршы көрәш эшчәнлеген камилләштерү максатларында;

Югары Ослан муниципаль районы Советы

карар итте:

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында муниципаль хезмәткәргә хәбәр итү»;

1.2. Нигезләмәнең 16 пунктыннан дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.3. Нигезләмәнең 18 пунктыннан икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.4. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 18.1 һәм 18.2 пунктлары белән тулыландырырга:

«18.1. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәтенең җаваплы затлары тарафыннан карала, ул хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча мотивацияләнгән бәяләмә әзерли;

«18.2. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча яисә әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасының бишенче абзацында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән уведомлениеләр, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәтенең җаваплы затлары мөрәҗәгатьне яисә хәбәрнамәне тапшырган муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә уздырырга, аңардан язма аңлатмалар алырга хокуклы, ә җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә аның урынбасары, махсус

вәкаләтле вәкилгә, билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә мөмкин. Мөрәҗәгать яисә белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать кергән көннән җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Запрослар җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яки белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәр кергән көннән алып 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел»;

1.5. Нигезләмәнең 19 пунктындагы «а» пунктчасында «3 көнлек срок» сүзләрен «10 көнлек» сүзләренә, «җиде көн» сүзләрен «20 көнгә» алмаштырырга;

1.6. Нигезләмәнең 20 пунктында «өченче абзацта күрсәтелгән гаризалар» сүзләрен «өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризалар» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. Нигезләмәнең 22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәр яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче граждан катнашында үткәрелә. Муниципаль хезмәткәр яисә граждан комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге турында әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә;

1.8. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 22.1 пункт белән тулыландырырга:

«22.1. Комиссия утырышлары муниципаль хезмәткәр яисә гражданин булмаганда түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә уведомлениедә муниципаль хезмәткәрнең яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге барлыгы күрсәтелмәгән булса;

б) әгәр муниципаль хезмәткәр яисә граждан комиссия утырышында шәхсән үзе катнашырга теләүче һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр ителгән булып, комиссия утырышына килмәсә»;

1.9. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 28.2 пункт белән тулыландырырга:

«28.2. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы "б" пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип танырга;

б) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә һәм (яисә) җирле үзидарә органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яисә аның барлыкка килүен булдырмау чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга киңәш итә»;

1.10. Нигезләмәнең 38 пунктында «3 көнлек срок» сүзләрен «7 көнлек срок» сүзләренә алмаштырырга.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Югары Ослан муниципаль районының җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр

конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәнең текстын яңа редакциядә расларга. (1 нче кушымта)

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының закон, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиятдинов